АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРАЗАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423750, Уразай авылы, Ленин урамы,
4 нче йорт. Тел.3-44-62.

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРАЗАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423750,дер.Уразаево, улица Центральная,
дом 4. Тел.3-44-62.

**КАРАР**
№20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
16.09.2019 ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” гы Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы “Җирле референдум турында” Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлеге Уставының 12 статьясы нигезендә

**1. Карар бирәм:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә: "2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем,балачактан инвалидлардан кала, алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү турында:
-торак пунктларда су челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, су чыганакларын ремонтлау һәм лицензияләү;
- сабантуй үткәрү урыннарын төзекләндерү;
- рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру ;
- зират территориясендә агач кисү;
- авыл җирлеге территориясендә агач кисү;
-ритуаль хезмәтләр өчен инвентарь сатып алу;
- зират коймасын ремонтлау;
-юлларны ремонтлау һәм карап тоту (ПГС һәм ЩПС салу, грейдерлау, кардан чистарту)
- һәйкәлне ремонтлау һәм реконструкцияләү ;
- җирлек торак пунктларында хуҗасыз территорияләрне ремонтлау һәм киртәләү;
-торак пунктларда урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру;
-урамнарнын яктырту электр челтәрләрен карап тоту;
- декларация алдыннан ГТСны тикшерү. “ӘЙЕ” “ЮК”

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган махсус мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә: ТР, Актаныш муниципаль районы, Уразай авылы, Узэк урам, 4 нче йорт, ТР, Актаныш муниципаль районы, Куян авылы, Узэк урам,57 нче йорт, ТР, Актаныш муниципаль районы, Мерэс авылы, Узэк урам,35а нче йорт ТР, Актаныш муниципаль районы, Ильчебай авылы, Узэк урам,19 нчы йорт, ТР,Актаныш муниципаль районы, Шэрип авылы, Узэк урам, 5 нче йорт Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уразай авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитэкчесе:** **/Шарипов Р.Р./**